## Февраль аенда кояш чыгу, кояш бату һәм намаз уку вакытлары

| Көннәр | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Кояш бата Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 6.54 | 8.24 | 13.05 | 15.33 | 17.25 | 18.55 |
| 2 | 6.52 | 8.22 | 13.05 | 15.35 | 17.27 | 18.57 |
| 3 | 6.52 | 8.22 | 13.05 | 15.35 | 17.27 | 18.57 |
| 4 | 6.49 | 8.19 | 13.05 | 15.38 | 17.31 | 19.01 |
| 5 | 6.47 | 8.17 | 13.05 | 15.40 | 17.33 | 19.03 |
| 6 | 6.45 | 8.15 | 13.05 | 15.42 | 17.35 | 19.05 |
| 7 | 6.43 | 8.13 | 13.05 | 15.44 | 17.37 | 19.07 |
| 8 | 6.41 | 8.11 | 13.05 | 15.46 | 17.39 | 19.09 |
| 9 | 6.40 | 8.10 | 13.05 | 15.48 | 17.41 | 19.11 |
| 10 | 6.40 | 8.10 | 13.05 | 15.48 | 17.41 | 19.11 |
| 11 | 6.36 | 8.06 | 13.05 | 15.51 | 17.45 | 19.15 |
| 12 | 6.34 | 8.04 | 13.05 | 15.53 | 17.47 | 19.17 |
| 13 | 6.32 | 8.02 | 13.05 | 15.55 | 17.49 | 19.19 |
| 14 | 6.30 | 8.00 | 13.05 | 15.57 | 17.51 | 19.21 |
| 15 | 6.28 | 7.58 | 13.05 | 15.58 | 17.53 | 19.23 |
| 16 | 6.26 | 7.56 | 13.05 | 16.00 | 17.55 | 19.25 |
| 17 | 6.26 | 7.56 | 13.05 | 16.00 | 17.55 | 19.25 |
| 18 | 6.24 | 7.54 | 13.05 | 16.02 | 17.57 | 19.27 |
| 19 | 6.19 | 7.49 | 13.05 | 16.06 | 18.01 | 19.31 |
| 20 | 6.17 | 7.47 | 13.05 | 16.07 | 18.02 | 19.32 |
| 21 | 6.15 | 7.45 | 13.05 | 16.09 | 18.04 | 19.34 |
| 22 | 6.13 | 7.43 | 13.05 | 16.11 | 18.06 | 19.36 |
| 23 | 6.11 | 7.41 | 13.05 | 16.13 | 18.08 | 19.38 |
| 24 | 6.09 | 7.39 | 13.05 | 16.14 | 18.10 | 19.40 |
| 25 | 6.09 | 7.39 | 13.05 | 16.14 | 18.10 | 19.40 |
| 26 | 6.04 | 7.34 | 13.05 | 16.18 | 18.14 | 19.44 |
| 27 | 6.02 | 7.32 | 13.05 | 16.19 | 18.16 | 19.46 |
| 28 | 6.00 | 7.30 | 13.05 | 16.21 | 18.18 | 19.48 |
| 29 | 6.00 | 7.30 | 13.05 | 16.21 | 18.18 | 19.48 |

*Намаз вакытлары турында мәгълүматларны Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте хезмәткәрләре үзерләде, мөфти Вагыйз хәзрәт ЯРУЛЛИН раслады. Җомга көннәре аерып күрсәтелгән.*


**Учредители: трудовой коллектив редакции газеты «Бердэмлек» и Региональное Духовное управление мусульман Самарской области.**

**Оештыручылар: «Бердәмлек» газетасы редакциясенең хезмәт коллективы һәм Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте.**





بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

# Кыйбла

№ 1
2012 ел
январь

„БЕРДӘМЛЕК” ГАЗЕТАСЫНЫҢ АЙЛЫК ДИНИ КУШЫМТАСЫ


***3 - 4 ФЕВРАЛЬ - МӘУЛИД БӘЙРӘМЕ***

## Мәүлид мөбарәк булсын!

Пәйгамбәребез (с.г.в.) туган көн Мәүлид кичәсе дип атала. Бу кичә Кадер кичәсеннән соң безнең өчен иң сөеклесе, кадерлесе. Бу көнне Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) тууына шатланучыларның гөнаһлары кичерелә, аның могҗизалы тормышы турында уку, тыңлау, сөйләү саваплы эшләрдән санала. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) туганчы кешелек дөньясы караңгылыкта, рухи төшенкелектә, томаналыкта яшәгән. Кешеләр кыргыйлашкан, хак дин онытылган, дөньяның бөтен илләре варварлыктан, усаллыктан әлсерәгән. Башка җирләрдәге кебек үк, Мәккәдә дә кансызлык соңгы чигенә җиткән, әхлаксызлык горурлык дәрәҗәсенең күрсәткече булып хезмәт итә башлаган. Хатын-кызларга түбәнсетеп караганнар, алар белән сату-алу иткәннәр. Ә хатын-кызның кыз бала тудыруы зур кайгы һәм хурлык булып кабул ителгән.

Кешелек дөньясының шушы коточкыч чорында Аллаһы Тәгалә яраткан затларның иң бөеге Мөхәммәд галәйһиссәләмгә җиде кат җир һәм җиде күк катламы, ягъни бөтен дөнья бертавыштан: «Хуш киләсең, Аллаһы Илчесе!» – дип тавыш биргән.

Мөхәммәд галәйһиссәләмнең дөньяга килүе, аның ислам динен таратуы кыргый Гарәбстан халкын иманга китергән. Томаналык, усаллык, рухи әхлаксызлык ислам тарафыннан юк ителгән. Шуннан башлап, ислам диненең нуры бөтен җиргә таралып, кешелекне усаллыктан, рухи түбәнлектән, кыргыйлыктан саклап килгән.

Мөхәммәд (с.г.в.) туган вакытта бик күп маҗаралы хәлләр күзәтелгән. Корәеш кабиләсе аксакалларыннан берсе булган Мөхәммәднең бабасы Габделмоталлиб түбәндәгеләрне әйтеп калдырган:

– Мөхәммәд (с.г.в.) туган төндә Кәгъбә тирәли йөрү йоласы башкара идем. Төн уртасыннан соң Кәгъбә Ибраһим яшәгән урынга эндәшеп дога укыды һәм әлеге сүзләрне әйтте: «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр! Мине мәҗүсилек пычраклыгыннан чистарттылар, дөньяның әшәкелегеннән, бозыклыгыннан арындырдылар».

Бөтен потлар ауды. Потларның иң зурысы – Хубан исемлесе дә егылды. Шуннан соң кемдер: «Әминә Мөхәммәдне тудырды», – диде. Мин Сафа тавына мендем. Шундый шау-шулы иде монда, әйтерсең, бөтен кошкортлар, җанварлар Мәккәгә җыелган.

Шул көнне Кисра сарае ишелде. Утка табынучыларның мең еллар буена янган уты сүнде. Сава диңгезе кипте.

*(“Татар мөселман календаре”ннан)*

***ВӘГАЗЬ***

## Исламга һәм дөньяга мөнәсәбәт

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

«Әл Гыймран» сүрәсенең 19 нчы аятендә: *«Чынлыкта, Аллаһы Тәгалә каршында хак дин – ислам дине»,* – диелә. Хаклык берәү генә була. Ислам дине хак дин булгач, башка диннәр ялгандыр.

Аллаһы Тәгалә дөньяларны ислам динендә генә яши алырлык итеп яраткан һәм барча мәхлукать фәкать ислам динендә генә яши ала. Адәм баласыннан башкалар һәрвакыт Аллаһыны зикер итәләр, Аллаһыга гына буйсыналар. Фәкать адәм баласы гына ирекле, ягъни теләсә - буйсына, теләмәсә - буйсынмыйча, итагатьсез кол булып яши һәм дөньяда ничек яшәешенә карап, яисә җәннәткә, яисә җәһәннәмгә ирешә. Әмма Аллаһы Тәгалә үзенең колларына битараф түгел, Аның рәхмәте чиксез. Ул кешеләргә үзләренең араларыннан пәйгамбәрләр җибәреп тора. Ул пәйгамбәрләр үзләренең халыкларын туры юлга өндиләр, Аллаһының берлеген танырга чакыралар. Ахырзаман пәйгамбәре булган сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм килгәч, пәйгамбәрлек килүдән туктый. Чөнки ул алып килгән дин, ул алып